## Башкарма комитет компетенциясе

Җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итү буенча Башкарма комитет компетенциясенә керә:

**1. Планлаштыру, бюджет һәм икътисадый үсеш өлкәсендә:**

1) шәһәр территориясендә урнашкан оешмалардан, оештыру-хокукый формаларына бәйсез рәвештә, шәһәр бюджеты проектларын, шәһәрнең социаль-икътисадый үсеше стратегиясен төзү өчен кирәкле мәгълүматларны соратып алу һәм җыю;

2) шәһәрнең социаль-икътисадый үсеш стратегиясен эшләү һәм тормышка ашыру;

3) шәһәрнең чыгым йөкләмәләрен билгеләү һәм үтәү;

4) әлеге Устав нигезендә муниципаль бурыч белән идарә итү;

5) шәһәр исеменнән муниципаль үзләштерүләр, шул исәптән шәһәр исеменнән кыйммәтле кәгазьләр чыгару һәм шәһәр бюджетына Россия Федерациясе бюджет системасының башка бюджетларыннан һәм кредит оешмаларыннан кредитлар җәлеп итү юлы белән гамәлгә ашыру;

6) Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы социаль-икътисадый үсешенең өстенлекләре һәм максатлары белән килештерелгән муниципаль идарә итүнең һәм шәһәрнең социаль-икътисадый үсешенең озак сроклы максатларын һәм бурычларын билгеләү;

7) Башкарма комитет вәкаләтләренә кертелгән мәсьәләләр буенча стратегик планлаштыру документларын эшләү, карап тикшерү, раслау (хуплау) һәм тормышка ашыру;

8) җирле үзидарә органнары тарафыннан расланган (хупланган) стратегик планлаштыру документларын гамәлгә ашыруны мониторинглау һәм контрольдә тоту;

9) стратегик планлаштыру өлкәсендә федераль законнар һәм муниципаль норматив хокукый актлар белән билгеләнгән башка вәкаләтләр.

---

*(Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Шәһәр Советының 2018 елның 27 апрелендәге 24/8 номерлы Карары редакциясенең 1 өлеше)*

---

**2. Муниципаль милеккә хуҗа булу, алардан файдалану һәм алар белән эш итү өлкәсендә:**

1) Муниципаль милеккә хуҗа булу, аннан файдалану һәм алар белән эш итү мәсьәләләрен Россия Федерациясе Конституциясе, федераль законнар, әлеге Устав һәм башка муниципаль хокукый актлар нигезендә муниципаль берәмлек исеменнән хәл итү;

2) физик һәм юридик затларга, Россия Федерациясе дәүләт хакимияте органнарына, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарына һәм башка муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына гамәлдәге законнарда һәм Шәһәр Советы карарларында каралган тәртиптә муниципаль милекне вакытлыча яисә даими файдалануга бирү, тартып алу, башка сату-алу гамәлләре башкару;

3) федераль законнар, Шәһәр Советы карарларында билгеләнгән тәртип һәм шартлар нигезендә муниципаль милекне приватизацияләү;

4) Шәһәр Советы билгеләгән тәртип нигезендә муниципаль предприятиеләрне һәм башка оешмаларны төзү, үзгәртеп кору, тибын үзгәртү, ликвидацияләү; муниципаль предприятиеләр һәм учреждениеләрнең максатларын, шартларын, эшчәнлек тәртибен билгеләү, аларның уставларын раслау, муниципаль предприятие һәм учреждение җитәкчеләрен вазыйфага билгеләү һәм вазыйфадан азат итү; аларның эшчәнлеге турында хисапларны тыңлау;

*(Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Шәһәр Советының 2010 елның 27 декабрендәге 7/16 номерлы Карары редакциясенең 2 өлеше, 4 пункты)*

5) Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы законнары нигезендә муниципаль учреждениеләр һәм предприятиеләр тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләргә тарифларны билгеләү һәм җайга салуны гамәлгә ашыру;

*(Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Шәһәр Советының 2006 елның 19 октябрендәге 15/4 номерлы Карары редакциясенең 5 пункты һәм 2009 елның 9 апрелендәге 40/6 номерлы Карары)*

6) муниципаль милекнең исәбен һәм реестрын алып бару;

7) муниципальара хуҗалык җәмгыятьләрен гамәлгә кую турында, ачык булмаган акционерлык җәмгыятьләре һәм җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятьләр рәвешендә, коммерцияле булмаган автоном коммерцияле булмаган оешмалар һәм фондлар рәвешендә оешмалар төзү турында Шәһәр Советы карарлары проектларын кертү.

*(Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Шәһәр Советының 2018 елның 11 декабрендәге 28/9 номерлы Карары редакциясенең 7 пункты)*

**3. Әйләнә-тирә мохитне саклау һәм табигый ресурслардан файдалану өлкәсендә:**

1) шәһәр чикләрендә әйләнә-тирә мохитне саклау чараларын оештыру;

2) җир асты байлыкларын файдалануга биргәндә территория халкының социаль-икътисадый һәм экологик мәнфәгатьләрен үтәүгә бәйле мәсьәләләрне хәл итүдә катнашу;

4) Әлеге объектларны тиешле территориядә булдыру очрагында һәм башка административ-территориаль берәмлек тарафыннан билгеләнә торган хуҗалык һәм башка төр эшчәнлекнең әйләнә-тирә мохиткә йогынты ясау мөмкинлеге булган очракта, экологик экспертиза объектларының дәүләт экологик экспертизасы эксперт комиссияләре утырышларында күзәтүчеләр сыйфатында катнашу өчен экспертларны делегат итеп җибәрү;

5) җәмәгатьчелек фикер алышулары, сораштыру, референдумнар, иҗтимагый экологик оешмаларның (берләшмәләрнең) һәм хәрәкәтләрнең гаризалары, экологик экспертиза объектлары турында мәгълүматлар нигезендә экологик экспертиза мәсьәләләре буенча үз вәкаләтләре чикләрендә карарлар кабул итү һәм гамәлгә ашыру;

6) экологик экспертизага тиешле хуҗалык һәм башка төр эшчәнлек турында җәмәгатьчелек фикер алышуларын оештыру, халык арасында сораштырулар, референдумнар үткәрү;

7) халык таләбе буенча иҗтимагый экологик экспертизалар оештыру;

8) тиешле муниципаль берәмлек территориясендә хуҗалык һәм башка төр эшчәнлек алып бару ниятләре турында экологик экспертиза өлкәсендә федераль башкарма хакимият органнарына хәбәр итү;

9) прокуратура органнарына, әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендә федераль башкарма хакимият органнарына һәм Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимияте органнарына экологик экспертиза объектын уңай дәүләт экологик экспертиза бәяләмәсеннән башка гамәлгә ашыра башлау турында хәбәр итү.

10) җирле әһәмияткә ия дәвалау-сәламәтләндерү урыннары һәм курортлар булдыру, аларны үстерү һәм саклауны тәэмин итү, шулай ук җирле әһәмияткә ия махсус саклана торган табигать территорияләрен саклау һәм алардан файдалану өлкәсендә муниципаль контрольне гамәлгә ашыру;

*(10 пункт Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Шәһәр Советының 2021 елның 3 ноябрендәге 9/5 номерлы Карары белән кертелгән);*
*(Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Шәһәр Советының 2018 елның 27 апрелендәге 24/8 номерлы Карары редакциясенең 3 өлеше)*

4. Шәһәр төзелеше, архитектура һәм җирдән файдалану өлкәсендә:

1) шәһәрнең генераль планын, торак районнарны планлаштыру проектларын, межалау проектларын һәм башка шәһәр бюджетыннан финанслана торган шәһәр төзелеше документларын, инженерлык тәэмин итүнең тармак схемаларын эшләүне башкаруга заказчы функцияләрен гамәлгә ашыру;

*(Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Шәһәр Советының 2007 елның июлендәге 23/4 номерлы Карары редакциясенең 1 пункты)*

2) шәһәрнең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен эшләү һәм аларны Шәһәр Советына раслауга бирү;

3) оешмаларга шәһәрдә муниципаль милектә булмаган электр, җылылык, газ, су, канализация, телекоммуникация һәм башка челтәрләр һәм корылмалар төзү схемалары һәм планнары буенча бәяләмәләр бирү;

4) адреслау объектларына адреслар бирү, шәһәр округы чикләрендә адресларны үзгәртү, юкка чыгару, мәгълүматны Дәүләт адреслар реестрында урнаштыру;

*(Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Шәһәр Советының 2014 елның 16 октябрендәге 33/17 номерлы Карары редакциясенең 4 пункты)*

5) төзелгән, үзгәртеп корылган капиталь төзелеш объектларын карау буенча комиссия төзү;

*(Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Шәһәр Советының 2013 елның 29 августындагы 26/17 номерлы Карары редакциясенең 5 пункты)*

6) Татарстан Республикасы территорияләрен шәһәр төзелеше планлаштыруының территориаль комплекслы схемаларын, Татарстан Республикасы территориясен төзекләндерү, инженерлык транспорт һәм социаль инфраструктураны үстерү схемаларын һәм проектларын, Татарстан Республикасы максатчан программаларының шәһәр төзелеше бүлекләрен һәм

Татарстан Республикасы территориясен социаль-икътисадый үстерү программаларын карап тикшерүдә һәм килештерүдә катнашу;

7) шәһәр төзелеше документларын эшләүне һәм гамәлгә ашыруны контрольдә тоту;

8) шәһәр төзелеше документларын эшләү өчен билгеләнгән тәртиптә шәһәр төзелеше йөкләмәләрен бирү;

9) муниципаль берәмлек территориясендә шәһәр төзелеше һәм проектлар, архитектура-сәнгать бизәлеше һәм төзекләндерү буенча документлар эшләүгә конкурслар оештыру һәм үткәрү;

10) гамәлдәге төзелеш планын (төп планын), корылмаларның һәм элемтә коммуникацияләренең, линия җиһазларының урнашу планын, җир төзелеше һәм шәһәр төзелеше документларының кадастрын алып бару;

11) халыкка хезмәт күрсәтүне гамәлгә ашыручы һәм шәһәрнең комплекслы социаль-икътисадый үсешен тәэмин итүче гамәлдәге һәм яңа төзелә торган, аерым торучы объектларның функциональ билгеләнешен генераль план нигезендә билгеләү;

12) Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы законнары нигезендә шәһәр территориясендә урнашкан капиталь төзелеш объектларын төзүгә, реконструкцияләүгә рөхсәт бирү;

---

*(Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Шәһәр Советының 2006 елның 19 октябрендәге 15/4 номерлы Карары редакциясенең 12 пункты, 2011 елның 15 декабрендәге 15/7 номерлы Карары)*

---

13) Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы законнары нигезендә шәһәр территориясендә урнашкан капиталь төзелеш объектларын төзегәндә, реконструкцияләгәндә объектларны файдалануга тапшыруга рөхсәт бирү;

---

*(Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Шәһәр Советының 2006 елның 19 октябрендәге 15/4 номерлы Карары редакциясенең 13 пункты, 2011 елның 15 декабрендәге 15/7 номерлы Карары, 2012 елның 20 декабрендәге 22/19 номерлы карары редакциясе)*

---

13.1) шәһәр территориясендә урнашкан капиталь төзелеш объектларының рөхсәт ителгән чик параметрларыннан читкә тайпылуына рөхсәт бирү;

13.2) шәһәр территориясендә урнашкан җир участогыннан, капиталь төзелеш объектыннан шартлы рәвештә рөхсәт ителгән файдалану төренә рөхсәт бирү;

13.3) шәһәр чикләрендә урнашкан җир участогының шәһәр төзелеше планын бирү;

---

*(Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Шәһәр Советының 2019 елның 6 декабрендәге 34/14 номерлы Карары редакциясенең 13 пункты);*

*(13.1-13.3 пунктлар Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Шәһәр Советының 2006 елның 19 октябрендәге 15/4 номерлы Карары белән кертелгән)*

---

13.4) биналарның, корылмаларның техник торышын карап тикшерү үткәрү һәм күрсәтелгән объектларга техник регламентларның конструктив һәм башка ышанычлылык характеристикаларына куела торган таләпләре,

проект документлары таләпләре нигезендә тиешле техник хезмәт күрсәтү, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексында каралган очракларда ачыкланган җитешсезлекләрне бетерү буенча тәкъдимнәр бирү;

*(13.4 пункт Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Шәһәр Советының 2012 елның 20 декабрендәге 22/19 номерлы Карары белән кертелгән)*

13.5) коммуналь инфраструктура системаларын комплекслы үстерү программаларын, транспорт инфраструктурасын комплекслы үстерү программаларын, шәһәрнең социаль инфраструктурасын комплекслы үстерү программаларын эшләү, раслау һәм тормышка ашыру;

*(13.5 пункт Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Шәһәр Советының 2013 елның 29 августындагы 26/17 номерлы Карары белән кертелгән, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Шәһәр Советының 2015 елның 27 февралендәге 38/14 номерлы Карары, 2015 елның 23 июлендәге 41/11 номерлы Карары редакциясе)*

13.6) җир участоклары һәм (яки) аларда урнашкан күчемсез милек объектларына хокукы булучылар инициативасы буенча территорияне комплекслы үстерү турында шартнамәләр төзү;

13.7) Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексында каралган очракларда, территорияне комплекслы үстерү турында карар кабул итү;

*(Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Шәһәр Советының 2021 елның 3 ноябрендәге 9/5 номерлы Карары редакциясенең 13.7 пункты);*
*(13.6, 13.7 пунктлар Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Шәһәр Советының 2018 елның 27 апрелендәге 24/8 номерлы Карары белән кертелгән)*

13.8) Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 7 өлешендәге 2 пунктында, 51.1 статьясындагы 8 өлешнең 3 пунктында һәм 55 статьясындагы 19 өлешнең 5 пунктында каралган белдерү кәгазьләрен шәһәр округлары территорияләрендә урнашкан җир участокларында индивидуаль торак төзелеше объектларын, бакча йортларын төзүне, реконструкцияләүне гамәлгә ашырганда җибәрү;

13.9) рөхсәтсез төзелгән корылманы сүтү яки рөхсәтсез төзелгән корылманы гражданлык законнарында каралган очракларда билгеләнгән таләпләргә туры китерү, рөхсәтсез төзелгән корылманы сүтү яки аны Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексында каралган очракларда билгеләнгән таләпләргә туры китерү турында карар кабул итү;

*(13.8, 13.9 пунктлар Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Шәһәр Советының 2018 елның 11 декабрендәге 28/9 номерлы Карары белән кертелгән)*

14) шәһәр территориясендә шәһәр төзелеше эшчәнлеген гамәлгә ашыруга кагылышлы өлешендә шәһәр төзелеше эшчәнлеген тәэмин итүнең дәүләт мәгълүмат системаларын алып бару һәм шәһәр төзелеше эшчәнлеген тәэмин итү буенча дәүләт мәгълүмат системаларында булган мәгълүматлар, документлар һәм материалларны бирү;

15) җир эшләренең сыйфатын һәм срокларын, төзекләндерүне тикшереп тору;

16) инвестицион контрактлар төзү өчен инвесторлар сайлап алу буенча конкурслар һәм аукционнар үткәрү;

*(Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Шәһәр Советының 2018 елның 11 декабрендәге 28/9 номерлы Карары редакциясенең 14 пункты)*

17) муниципаль милектә булган җир участоклары һәм дәүләт милке булган җирләр белән муниципаль берәмлек территориясендә дәүләт милке саналу чикләнгәнче идарә итү һәм эш итү;

18) җир участокларын сату яки җир участокларын арендалау шартнамәләрен төзү хокукын сату (аукционнар, конкурслар) үткәрүне оештыру;

19) муниципаль берәмлек территориясендә җир төзелеше үткәрү турында карар кабул итү;

20) җир участогын кадастр планында яки кадастр картасында урнаштыру схемасын раслау;

*(Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Шәһәр Советының 2009 елның 10 сентябрендәге 42/7 номерлы Карары редакциясенең 20 пункты)*

21) җир өчен түләү алу;

22) шәһәр бюджетына аренда түләүләре кертелүгә контрольне гамәлгә ашыру;

*(Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Шәһәр Советының 2006 елның 19 октябрендәге 15/4 номерлы Карары редакциясенең 22 пункты)*

23) шәһәр округы чикләрендә муниципаль җир контролен гамәлгә ашыру;

*(Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Шәһәр Советының 2014 елның 16 октябрендәге 33/17 номерлы Карары редакциясенең 23 пункты)*

24) җир участокларын билгеләнгән тәртиптә муниципаль ихтыяҗлар өчен алу;

*(Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Шәһәр Советының 2015 елның 27 февралендәге 38/14 номерлы Карары редакциясенең 24 пункты)*

26) җир участокларын гамәлдәге законнарда каралган хокуклар һәм максатлар турында шәһәр төзелеше документлары белән расланган шәһәрнең Генераль планы нигезендә бирү;

27) реклама конструкцияләрен урнаштыру схемасын раслау, шәһәр территориясендә реклама конструкцияләрен урнаштыруга һәм эксплуатацияләүгә рөхсәт бирү һәм гамәлдән чыгару, реклама конструкцияләрен демонтажлауга күрсәтмәләр бирү;

*(27 пункт Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Шәһәр Советының 2006 елның 19 октябрендәге 15/4 номерлы Карары белән кертелгән, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Шәһәр Советының 2013 елның 29 августындагы 26/17 номерлы Карары редакциясе)*

28) Федераль закон нигезендә комплекслы кадастр эшләрен башкаруны оештыру һәм территориянең карта-планын раслау;

*(28 пункт Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Шәһәр Советының 2015 елның 27 февралендәге 38/14 номерлы Карары белән кертелгән, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Шәһәр Советының 2021 елның 27 маендагы 7/6 номерлы Карары редакциясе)*

29) шәһәр округы территориясендә элек исәпкә алынган күчемсез милек объектларына хокуклары булучыларны ачыклау буенча чаралар күрү һәм үткәрү, күчемсез милек объектларының әлеге хокук ияләре турында мәгълүматларны Бердәм дәүләт күчемсез милек реестрына кертү өчен җибәрү.

*(29 пункт Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Шәһәр Советының 2021 елның 27 маендагы 7/6 номерлы Карары белән кертелгән)*

**5. Төзелеш өлкәсендә:**

1) муниципаль берәмлек чикләрендә, гомуми файдаланудагы автомобиль юлларыннан, күперләрдән һәм федераль һәм региональ әһәмияткә ия башка транспорт корылмаларыннан тыш, инженерлык, социаль һәм җитештерү инфраструктуралары, гомуми файдаланудагы автомобиль юллары, күперләр һәм башка транспорт инженерлык корылмалары төзү, реконструкцияләү, капиталь ремонтлауны оештыру һәм финанслауны тәэмин итү, заказчы функцияләрен гамәлгә ашыру;

2) төзелеш, төзелеш материаллары һәм конструкцияләр сәнәгате өлкәсендә оешмалар эшчәнлеген координацияләү һәм идарә итү;

3) шәһәрнең социаль-икътисадый үсеш прогнозларын эшләүдә катнашу, шул исәптән төзелеш комплексының социаль-икътисадый үсешенең комплекслы прогнозын формалаштыру;

4) торак төзелешен үстерү һәм аны тормышка ашыруны тәэмин итү программаларын формалаштыру;

5) шәһәр объектларын төзүнең берләштерелгән программасын формалаштыру һәм тормышка ашыруны тәэмин итү;

6) төзелеш өлкәсендә конференцияләр, семинарлар, күргәзмәләр һәм башка чаралар оештыру.

**6. Мобилизация әзерлеге һәм мобилизацияләү өлкәсендә:**

1) муниципаль берәмлектә мобилизация әзерлеген һәм мобилизацияләүне оештыру һәм тәэмин итү;

2) икътисадның мобилизация планын билгеләнгән тәртиптә эшләү;

3) хәрби комиссариатларга тыныч вакытта һәм мобилизация игълан иткәндә аларның мобилизация эшендә ярдәм күрсәтү;

4) билгеләнгән тәртиптә муниципаль берәмлек җирле үзидарә органнарының идарә итү запас пунктларын төзү һәм әлеге пунктларны хәрби вакыт шартларында эшләү өчен әзерләү.

**7. Халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән саклау, гражданнар оборонасы һәм беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итү өлкәсендә:**

*(Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Шәһәр Советының 2007 елның 25 декабрендәге 28/10 номерлы Карары редакциясендәге абзац)*

1) халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән саклау, шулай ук халыкны гадәттән тыш хәлләрдән саклануга әзерләү өчен кирәкле көчләрне һәм чараларны әзерләү һәм әзер тотуны гамәлгә ашыру;

*(1 пункт Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Шәһәр Советының 2019 елның 1 августындагы 32/13 номерлы Карары белән кертелгән)*

2) барлыкка килгән гадәттән тыш хәлләрне муниципаль характердагы гадәттән тыш хәлләргә кертү, гадәттән тыш хәлләрдә эвакуация чаралары үткәрү һәм аларны муниципаль берәмлек территориясендә үткәрүне оештыру турында карар кабул итү;

*(Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Шәһәр Советының 2019 елның 6 декабрендәге 34/14 номерлы Карары редакциясенең 2 пункты)*

3) Халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән саклау өлкәсендә мәгълүмат җыю һәм алмашу, халыкка үз вакытында хәбәр итү һәм мәгълүмат бирү, шул исәптән кешеләр күпләп җыела торган урыннарда халыкка җиткерүнең һәм хәбәр итүнең махсуслаштырылган техник чараларын кулланып, гадәттән тыш хәлләр барлыкка килү куркынычы турында яисә килеп чыгу турында халыкка хәбәр итүне билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашыру;

*(Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Шәһәр Советының 2009 елның 9 апрелендәге 49/6 номерлы Карары редакциясенең 3 пункты)*

4) халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән саклау өлкәсендәге чараларны финанслауны гамәлгә ашыру;

5) гадәттән тыш хәлләрне бетерү өчен матди ресурс резервларын булдыру, урнаштыру, саклау һәм тулыландыру;

6) авария-коткару һәм башка кичектергесез эшләрне булган чаралар чикләрендә оештыру һәм уздыру, шулай ук аларны үткәргәндә җәмәгать тәртибен саклау, үз көчләре һәм чаралары җитмәгәндә, Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнарына ярдәм сорап мөрәҗәгать итү;

7) Башкарма комитет каршында халыкны һәм муниципаль берәмлек территорияләрен гадәттән тыш хәлләрдән саклау өлкәсендә бурычларны хәл итүгә махсус вәкаләтле даими эшләүче идарә итү органнарын төзү;

*(Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Шәһәр Советының 2009 елның 9 апрелендәге 40/6 номерлы Карары редакциясенең 7 пункты)*

7.1) гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү буенча бердәм дәүләт системасының тиешле идарә органнары һәм көчләре өчен югары әзерлек һәм гадәттән тыш хәл режимын кертү;

7.2) «Халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклау турында» 1994 елның 21 декабрендәге, 68-ФЗ Федераль законның 4.1 статьясының 8 пунктында билгеләнгән тәртиптә җавап бирүнең җирле дәрәҗәсен билгеләү;

*(Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Шәһәр Советының 2019 елның 1 августындагы 32/13 номерлы Карары редакциясенең 7.2 пункты)*

7.3) бердәм «112» номеры буенча экстрен оператив хезмәтләрне чакыруны тәэмин итү системасын төзү, эксплуатацияләү һәм үстерүдә катнашу;

*(Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Шәһәр Советының 2013 елның 29 августындагы 26/17 номерлы Карары редакциясенең 7.1 – 7.3 пунктлары)*

7.4) гадәттән тыш хәлләр турында халыкка хәбәр итү һәм мәгълүмат бирү муниципаль системаларын булдыралар һәм даими әзерлектә тоталар;

7.5) халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән саклау өлкәсендә мәгълүмат җыюны һәм мондый мәгълүмат алмашуны гамәлгә ашыралар, шул исәптән гадәттән тыш хәлләр барлыкка килү куркынычы турында яисә барлыкка килү турында халыкка ашыгыч хәбәр итүнең комплекслы системасын кулланып, гадәттән тыш хәлләр барлыкка килү куркынычы турында яисә килеп чыгу турында халыкка үз вакытында хәбәр итүне тәэмин итәләр;

*(7.4, 7.5 пунктлары Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Шәһәр Советының 2014 елның 16 октябрендәге 33/17 номерлы Карары белән кертелгән)*

7.6) муниципаль берәмлек территориясендә гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү буенча гамәлләр планын эшләү һәм раслау;

*(7.6 пункт Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Шәһәр Советының 2019 елның 6 декабрендәге 34/14 номерлы Карары белән кертелгән)*

8) табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү буенча гамәлләр планын эшләү һәм тормышка ашыру;

9) халыкны һәм муниципаль берәмлек территорияләрен гадәттән тыш хәлләрдән саклау өлкәсендә максатчан программалар эшләү һәм аларны тормышка ашыру;

10) муниципаль берәмлек территориясендә профессиональ авария-коткару хезмәтләрен, авария-коткару формированиеләрен төзү;

11) муниципаль берәмлекнең су объектларында массакүләм ял итү, коену, туризм һәм спорт урыннарын билгеләү;

12) Татарстан Республикасы кече суднолар буенча дәүләт инспекциясе һәм санитар-эпидемиологик күзәтчелекне гамәлгә ашыручы тиешле органнар белән килештереп, муниципаль берәмлек сулыкларында ярышлар, бәйрәмнәр һәм башка массакүләм чаралар уздыру урыннарын билгеләү;

13) муниципаль берәмлек пляжларында коену сезоны чорында коткару постларын булдыруны оештыру;

14) Гражданнар оборонасы буенча чаралар үткәрү, халыкны саклауның гражданнар оборонасы планнарын эшләү һәм тормышка ашыру;

15) Гражданнар оборонасы максатларында азык-төлек запасларын, медицина шәхси саклану чаралары һәм башка чараларны булдыру һәм карап тоту;

16) халыкны, матди һәм мәдәни кыйммәтләрне куркынычсыз районнарга эвакуацияләү буенча чаралар үткәрү;

17) Гражданнар оборонасы чараларын оештырганда һәм үткәргәндә, Россия Федерациясе законнары нигезендә мобилизация әзерлеге вакытында автомобиль юлларыннан файдалану, халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән саклау өлкәсендә Россия Федерациясе законнары нигезендә автомобиль юлларында гадәттән тыш хәлләр нәтиҗәләрен бетерү;

18) ирекле янгын сүндерү сагын оештыру, шулай ук гражданнарның беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын башка формаларда тәэмин итүдә катнашуы өчен шартлар тудыру;

19) янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү чараларын шәһәр территориясе үсеше планнарына, схемаларына һәм программаларына кертү;

20) Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарына янгын куркынычсызлыгы чаралары турында халыкка мәгълүмат бирүдә, шул исәптән халык җыелышларын оештыру һәм уздыру юлы белән ярдәм күрсәтү;

21) янгын куркынычы арткан очракта, янгынга каршы махсус режим билгеләү;

*(17 -21 пунктлар Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Шәһәр Советының 2007 елның 25 декабрендәге 28/10 номерлы Карары белән кертелгән)*

22) террорчылыкны профилактикалау, шулай ук аның күренешләре нәтиҗәләрен минимальләштерү һәм (яки) бетерү өлкәсендә муниципаль программаларны эшли һәм гамәлгә ашыра;

23) террорчылыкның асылын һәм аның иҗтимагый куркынычын аңлату, шулай ук гражданнарда террорчылык идеологиясен формалаштыру буенча, шул исәптән мәгълүмати материаллар, басма продукция тарату, аңлату эшләре һәм башка чаралар үткәрү юлы белән мәгълүмат-пропаганда чараларын оештыралар һәм үткәрәләр;

24) террорчылыкны профилактикалау, шулай ук федераль башкарма хакимият органнары һәм (яки) Россия Федерациясе субъекты башкарма хакимияте органнары тарафыннан оештырыла торган аның күренешләре нәтиҗәләрен минимальләштерү һәм (яки) бетерү буенча чараларда катнашалар;

25) муниципаль милектә булган яки җирле үзидарә органнары карамагында булган объектларның террорчылыкка каршы сакланышына карата таләпләрне үтәүне тәэмин итәләр;

26) террорчылыкны профилактикалауда катнашу мәсьәләләре буенча, шулай ук аның күренешләренең нәтиҗәләрен минимальләштерү һәм (яки) бетерү мәсьәләләре буенча тәкъдимнәрне Россия Федерациясе субъектының башкарма хакимияте органнарына җибәрәләр;

27) террорчылыкны профилактикалауда катнашу буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итү, шулай ук аның күренешләре нәтиҗәләрен минимальләштерү һәм (яки) бетерү буенча башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыралар;

*(22 -27 пунктлар Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Шәһәр Советының 2017 елның 22 февралендәге 15/10 номерлы Карары белән кертелгән)*

**8. Законлылыкны, хокук тәртибен тәэмин итү, гражданнарның хокукларын һәм ирекләрен саклау өлкәсендә:**

1) муниципаль милиция эшчәнлеген һәм аны тотуны билгеләнгән тәртиптә оештыру;

2) җыелышлар, митинглар, демонстрацияләр, урам йөрешләре, пикетлар оештыручыга ярдәм күрсәтү максатында гамәлдәге законнар нигезендә вәкаләтле вәкилне билгеләү;

3) присяжный утырышчылар исемлеген төзү;

4) билгеләнгән тәртиптә хокук саклау органнары белән хезмәттәшлек итү;

5) җинаять-башкарма инспекцияләре белән килешенү нигезендә, шәһәрдә урнашкан муниципаль унитар предприятиеләрдә төзәтү эшләренә хөкем ителгәннәр өчен җәза үтәү урыннарын һәм мәҗбүри эш төрләрен билгеләү;

*(Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Шәһәр Советының 2006 елның 19 октябрендәге 15/4 номерлы Карары редакциясенең 5 пункты)*

6) шәһәр территориясендә эш бирүчеләр – шәхси эшмәкәрләр булмаган физик затлар, хезмәткәрләр белән төзелгән хезмәт килешүләрен теркәү.

*(6 пункт Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Шәһәр Советының 2006 елның 19 октябрендәге 15/4 номерлы Карары белән кертелгән)*

7) җәмәгать тәртибен саклауда катнашучы гражданнарга, аларның берләшмәләренә ярдәм күрсәтү, халык дружиналары эшчәнлеге өчен шартлар тудыру;

*(7 пункт Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Шәһәр Советының 2014 елның 16 октябрендәге 33/17 номерлы Карары белән кертелгән)*

8) федераль законнар белән билгеләнгән тәртиптә һәм шартларда оешмалар тарафыннан хезмәт күрсәтү сыйфатын бәйсез бәяләүне үткәрүне оештыру өчен шартлар тудыру, шулай ук ведомство буйсынуындагы оешмалар җитәкчеләре эшчәнлеген бәяләгәндә оешмалар тарафыннан хезмәт күрсәтү шартларын бәйсез бәяләү нәтиҗәләрен куллану һәм оешмалар тарафыннан хезмәт күрсәтү шартларын бәйсез бәяләү нәтиҗәләре буенча ачыкланган җитешсезлекләрне бетерү буенча чаралар күрүне федераль законнар нигезендә тикшереп тору;

*(8 пункт Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Шәһәр Советының 2015 елның 27 февралендәге 38/14 номерлы Карары белән кертелгән, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Шәһәр Советының 2018 елның 27 апрелендәге 28/8 номерлы Карары редакциясе)*

9) «Россия Федерациясендә хокук бозуларны профилактикалау системасы нигезләре турында» Федераль законда каралган хокук бозуларны профилактикалау өлкәсендәге чараларны гамәлгә ашыру;

*(9 пункт Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Шәһәр Советының 2017 елның 22 февралендәге 15/10 номерлы Карары белән кертелгән)*

**9. Торак хуҗалыгы, коммуналь хезмәтләр, транспорт, урман мөнәсәбәтләре өлкәсендә:**

*(Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Шәһәр Советының 2009 елның 9 апрелендәге 40/6 номерлы Карары редакциясендәге беренче абзац)*

4) торак урыннары өчен түләү күләмен федераль законнарда билгеләнгән вәкаләтләр чикләрендә, Шәһәр Советы билгеләгән тәртип нигезендә билгеләү;

6) гамәлдәге законнарда каралган очракларда торак фондын эксплуатацияләү һәм карап тоту;

6.1) күпфатирлы йортларда торак урыннары милекчеләренә капиталь ремонт фондын формалаштыру ысуллары, капиталь ремонт фондын формалаштыру ысулын сайлау тәртибе турында мәгълүмат бирү;

6.2) күпфатирлы йортларда гомуми милеккә капиталь ремонт үткәргәндә кичектергесез ихтыяҗ туганда бюджет акчалары хисабына кире кайтарыла һәм (яки) кире кайтарылмый торган нигездә ярдәм күрсәтү тәртибен һәм очракларның исемлеген раслау;

*(Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Шәһәр Советының 2018 елның 27 апрелендәге 24/8 номерлы Карары редакциясенең 6.1, 6.2 пунктлары)*

7) муниципаль милектә булган социаль, көнкүреш, коммуналь хуҗалык объектларын, торак булмаган биналарны карап тоту;

8) законнарда каралган очракларда билгеләнгән тәртиптә ачык конкурслар үткәрү;

9) шәһәр территориясендә урнашкан торак фондын, социаль, көнкүреш, коммуналь хуҗалык объектларыннан файдалану һәм аларны карап тоту буенча күпфатирлы йортлар белән идарә итү өчен, билгеләнгән тәртиптә кабул ителгән муниципаль хокукый актлар нигезендә, торак милекчеләре ширкәтләре, яисә торак кооперативлары, яисә башка махсуслаштырылган кулланучылар кооперативлары тарафыннан шартлар тудыру;

*(Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Шәһәр Советының 2006 елның 19 октябрендәге 15/4 номерлы Карары редакциясенең 9 пункты)*

9.1) коммуналь комплекс оешмаларының энергия саклау һәм энергетика нәтиҗәлелеген арттыру өлкәсендәге программаларына, җирле үзидарә органнары тарафыннан билгеләнергә тиешле товарларга бәяләр (тарифлар) билгеләү;

9.2) энергия саклау һәм энергетика нәтиҗәлелеген арттыру өлкәсендә муниципаль программаларны раслау һәм гамәлгә ашыру;

9.3) муниципаль берәмлек чикләрендә муниципаль торак фонды булган күпфатирлы йортларга энергетика тикшерүен үткәрүне оештыру, шулай ук энергия саклау һәм энергетика нәтиҗәлелеген арттыру турындагы законнарда каралган башка чараларны оештыру һәм үткәрү;

*(9.1-9.3 пунктлар Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Шәһәр Советының 2010 елның 31 мартындагы 47/7 номерлы Карары белән кертелгән)*

9.3.1) энергия саклау һәм энергетика нәтиҗәлелеген арттыру буенча чараларны координацияләү һәм муниципаль учреждениеләр, муниципаль унитар предприятиеләр тарафыннан аларны үткәрүне контрольдә тоту;

9.3.2) «Энергия саклау һәм энергетика нәтиҗәлелеген арттыру турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2009 елның 23 ноябрендәге 261-ФЗ номерлы Федераль закон, башка федераль законнар белән җирле үзидарә органнары вәкаләтләренә кертелгән

энергия саклау һәм энергетика нәтиҗәлелеген арттыру өлкәсендә башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыру;

*(9.3.1, 9.3.2 пунктлар Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Шәһәр Советының 2018 елның 11 декабрендәге 28/9 номерлы Карары белән кертелгән)*

9.4) шәһәр территориясендә кулланучыларны ышанычлы җылылык белән тәэмин итүне оештыру, шул исәптән җылылык белән тәэмин итүче оешмалар яки җылылык челтәрләре оешмалары тарафыннан үз йөкләмәләрен үтәмәгән яисә күрсәтелгән оешмалар үз йөкләмәләрен үтәүдән баш тарткан очракта, кулланучыларны җылылык белән тәэмин итүне оештыру буенча чаралар күрү;

9.4.1) җылылык белән тәэмин итү объектларын төзү, реконструкцияләү һәм (яки) модернизацияләү буенча бердәм җылылык белән тәэмин итүче оешма тарафыннан йөкләмәләрнең үтәлешенә муниципаль контрольне гамәлгә ашыру;

*(9.4.1 пункт Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Шәһәр Советының 2017 елның 15 декабрендәге 21/16 номерлы Карары белән кертелгән, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Шәһәр Советының 2021 елның 3 ноябрендәге 9/15 номерлы Карары редакциясе)*

9.4.2) җылылык белән тәэмин итү шартнамәсендә җылылык белән тәэмин итүнең сыйфат параметрлары һәм (яки) җылылык белән тәэмин итүнең бәя зоналарында, бәхәсләрне судка кадәр җайга салу тәртибендә чагылдырыла торган параметрлар күрсәткечләрен һәм җылылык белән тәэмин итү шартнамәсенә кертү өчен тәкъдим ителә торган шундый параметрларның зурлыкларын билгеләгәндә Бердәм җылылык белән тәэмин итү оешмасы белән җылылык энергиясен кулланучы арасында килеп туган каршылыкларны карап тикшерү һәм җылылык белән тәэмин итү шартнамәсенә кертү өчен тәкъдим ителә торган мондый параметрларның зурлыгын билгеләү;

*(9.4.2 пункт Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Шәһәр Советының 2018 елның 27 апрелендәге 24/8 номерлы Карары белән кертелгән)*

9.5) җылылык белән тәэмин итүнең ышанычлылыгы мәсьәләләре буенча кулланучылар мөрәҗәгатьләрен Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан расланган җылылык белән тәэмин итүне оештыру кагыйдәләрендә билгеләнгән тәртиптә карап тикшерү;

9.6) җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыруга вәкаләтле башкарма хакимиятнең федераль органы тарафыннан расланган җылылык чорына әзерлекне бәяләү кагыйдәләрендә билгеләнгән таләпләрне үтәү һәм җылылык белән тәэмин итүче оешмаларның, җылылык челтәрләре оешмаларының, кулланучыларның аерым категорияләренең җылыту чорына әзерлеген тикшереп тору;

9.7) «Җылылык белән тәэмин итү турында» Федераль законда билгеләнгән очракларда, җылылык энергиясе чыганакларын, җылылык челтәрләрен ремонтлауга һәм эксплуатацияләүдән чыгаруга килешенү;

*(Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Шәһәр Советының 2018 елның 27 апрелендәге 24/8 номерлы Карары редакциясенең 9.7 пункты)*

9.8) жылылык белән тәэмин итү өлкәсендә эшчәнлекнең җайга салына торган төрләрен хәл итүче оешмаларның инвестиция программаларын килештерү, электр энергетикасы турында Россия Федерациясе законнары нигезендә килештерелә торган программалардан тыш;

*(Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Шәһәр Советының 2018 елның 11 декабрендәге 28/9 номерлы Карары редакциясенең 9.8 пункты)*

9.8.1) жылылык белән тәэмин итү өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыруга вәкаләтле федераль башкарма хакимият органына жылылык белән тәэмин итү схемасы проектын яки шәһәрне жылылык белән тәэмин итү схемаларына таләпләр, аларны эшләү, раслау һәм актуальләштерү тәртибенә туры китереп эшләнгән актуальләштерелгән жылылык белән тәэмин итү схемасы проектын эшләү һәм жибәрү;

*(9.8.1 пункт Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Шәһәр Советының 2018 елның 11 декабрендәге 7/6 номерлы Карары белән кертелгән)*

9.9) Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә жылылык белән тәэмин итүне оештыру өлкәсендә башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыру;

*(9.4-9.9 пунктлар Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Шәһәр Советының 2010 елның 27 декабрендәге 7/6 номерлы Карары белән кертелгән)*

9.10) халыкны су белән тәэмин итүне оештыру, шул исәптән кайнар су белән тәэмин итүне, салкын су белән тәэмин итүне һәм (яки) кулланган суларны агызуны хәл итүче оешмалар тарафыннан үз йөкләмәләрен, яки күрсәтелгән оешмаларның үз йөкләмәләрен үтәүдән баш тартулары очрагында, халыкны су белән тәэмин итүне һәм (яки) кулланган суларны агызуны оештыру буенча чаралар күрү;

9.11) шәһәрнең үзәкләштерелгән салкын су белән тәэмин итү һәм (яки) кулланган суларны агызу системасы өчен гарантияле оешма билгеләү;

9.12) үзәкләштерелгән кайнар су белән тәэмин итү, салкын су белән тәэмин итү һәм (яки) кулланган суларны агызу системалары объектларын ремонтка һәм эксплуатацияләүгә чыгаруны килештерү;

9.13) шәһәрне су белән тәэмин итү һәм кулланган суларны агызу схемаларын раслау;

9.14) инвестиция программаларын эшләүгә техник йөкләмәләрне раслау;

9.15) инвестиция программаларын килештерү;

9.17) жылылык белән тәэмин итү (кайнар су белән тәэмин итү) ачык системаларыннан файдаланып, кайнар су белән тәэмин итүне туктату тәртибе һәм сроклары турында һәм капиталь төзелеш объектларына «Су белән тәэмин итү һәм кулланган суларны агызу турында» Федераль законда каралган очракларда, кайнар су белән тәэмин итүнең башка системасына тоташтырылган абонентларны күчерүне оештыру хакында карарлар кабул итү;

9.18) «Су белән тәэмин итү һәм кулланган суларны агызу турында» Федераль законда каралган очракларда, су белән тәэмин итү һәм кулланган

суларны агызу өлкәсендә җайга салына торган эшчәнлекне гамәлгә ашыру шартлары турында шартнамәләр төзү;

9.18.1) җыентык суларның составы нормативларын билгеләү;

*(9.18.1 пункт Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Шәһәр Советының 2018 елның 11 декабрендәге 28/9 номерлы Карары белән кертелгән)*

9.19) «Су белән тәэмин итү һәм кулланган суларны агызу турында» Федераль законда билгеләнгән башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыру;

9.20) шәһәр территориясендә радиоактив калдыкларны саклау пунктларын Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 3 бүлегендә һәм «Атом энергиясеннән файдалану турында» 1995 елның 21 ноябрендәге 170-ФЗ номерлы Федераль законда билгеләнгән тәртиптә урнаштыру турында карарлар кабул итүдә катнашу;

9.21) Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә радиоактив калдыклар белән эш итү өлкәсендә башка вәкаләтләр;

*(9.10 - 9.21 пунктлар Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Шәһәр Советының 2012 елның 5 июлендәге 19/15 номерлы Карары белән кертелгән)*

9.22) торак-коммуналь хуҗалыкны, сәнәгать һәм башка оешмаларны газлаштыруның төбәкара һәм төбәк программалары нигезендә халыкны газ куллануга әзерләү;

9.23) халыкны газ белән тәэмин итү өчен файдаланыла торган газ белән тәэмин итү объектларының урнашу схемаларын килештерү;

*(9.22 - 9.23 пунктлар Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Шәһәр Советының 2019 елның 1 августындагы 32/13 номерлы Карары белән кертелгән)*

10) муниципаль милектә булган торак урыннарны сату турында билгеләнгән тәртиптә карар кабул итү;

11) каты коммуналь калдыкларны җыю, (шул исәптән аерып җыю) , ташу, эшкәртү, утильләштерү, зарарсызландыру, күмү эшчәнлеген оештыруда катнашу;

*(Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Шәһәр Советының 2018 елның 27 апрелендәге 24/8 номерлы Карары редакциясенең 11 пункты)*

11.1) урамнарны яктыртуны оештыру һәм урам исемнәре һәм йорт номерлары белән күрсәткечләр кую;

*(11.1 пункт Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Шәһәр Советының 2010 елның 31 мартындагы 47/7 номерлы Карары белән кертелгән)*

11.2) каты коммуналь калдыклар туплау урыннарын (мәйданчыкларын) булдыру һәм карап тоту, Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән очраклардан тыш, мондый бурыч башка затларга йөкләнгән булса;

11.3) каты коммуналь калдыклар туплау урыннарын (мәйданчыкларын) урнаштыру схемасын билгеләү һәм каты коммуналь калдыклар туплау урыннары (мәйданчыклары) реестрын алып бару;

11.4) каты коммуналь калдыклар белән эш итү өлкәсендә экологик тәрбия оештыру һәм экологик культура формалаштыру;

*(11.2-11.4 пунктлар Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Шәһәр Советының 2018 елның 27 апрелендәге 24/8 номерлы Карары белән кертелгән)*

12) территориаль иҗтимагый үзидарә уставын Шәһәр Советы билгеләгән тәртиптә теркәү;

13) җирләү эшен оештыру, ритуаль хезмәтләр күрсәтү; җирләү урыннарын төзү, реконструкцияләү һәм карап тоту;

14) төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контрольне гамәлгә ашыру, аның предметы шәһәр округы территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен, шул исәптән социаль, инженерлык һәм транспорт инфраструктурасы объектларының һәм күрсәтелә торган хезмәтләрнең инвалидлар ала алырлык булуын тәэмин итү таләпләрен үтәү (төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда, мәҗбүри таләпләрне (куркынычсызлык мониторингы) үтәүне күзәтү барышында ачыкланган мәҗбүри таләпләрне бозуларны бетерү турында күрсәтмә бирелергә мөмкин, төзекләндерү кагыйдәләре нигезендә шәһәр территориясен төзекләндерүне оештыру, шулай ук шәһәр урманнарын, шәһәр чикләрендә урнашкан махсус саклана торган табигать территорияләренең урманнарын файдалану, саклау, яңадан торгызуны оештыру;

*(Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Шәһәр Советының 2018 елның 27 апрелендәге 24/8 номерлы Карары редакциясенең 9.7 пункты)*

14.1) арендалау максатында урман ресурслары күләме берәмлеге өчен түләү ставкаларын һәм мондый урман кишәрлегенең мәйданы берәмлеге өчен түләү ставкаларын билгеләү;

14.2) агач күләме берәмлеге өчен түләү ставкаларын билгеләү;

14.3) урман хуҗалыгы регламентларын эшләү һәм раслау, шулай ук урманнарны үзләштерү проектларына муниципаль экспертиза үткәрү;

14.4) муниципаль урман контролен гамәлгә ашыру;

(Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Шәһәр Советының 2011 елның 15 декабрендәге 15/7 номерлы Карары редакциясенең 14.4 пункты)

*(14.1-14.4 пунктлары Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Шәһәр Советының 2009 елның 9 апрелендәге 40/06 номерлы Карары белән кертелгән)*

14.5) урманнарда ягшын куркынычсызлыгы чараларын гамәлгә ашыруны оештыру;

*(Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Шәһәр Советының 2011 елның 15 декабрендәге 15/7 номерлы Карары редакциясенең 14.5 пункты)*

14.6) шәһәр округы территориясендә яшәүче хуҗасыз хайваннар белән эш алып бару эшчәнлеген гамәлгә ашыру;

*(14.6 пункт Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Шәһәр Советының 2015 елның 23 июлендәге 41/11 номерлы Карары белән кертелгән, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Шәһәр Советының 2019 елның 1 августындагы 32/13 номерлы Карары редакциясе)*

15) муниципаль берәмлек чикләрендә халыкка транспорт хезмәте күрсәтү өчен шартлар тудыру һәм халыкка транспорт хезмәте күрсәтүне оештыру;

15.1) муниципаль маршрутлар буенча пассажирлар йөртүгә заказчы функцияләрен гамәлгә ашыру;

*(15.1 пункт Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Шәһәр Советының 2009 елның 10 сентябрендәге 42/7 номерлы Карары белән кертелгән)*

16) муниципаль маршрутларда пассажирларга хезмәт күрсәтү сыйфатын тикшереп тору;

18) нормативтан тыш күчәр йөкләнеше һәм габаритлары булган транспорт чараларының шәһәр автомобиль юллары буенча хәрәкәтен оештыру.

*(Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Шәһәр Советының 2009 елның 10 сентябрендәге 42/7 номерлы Карары редакциясенең 16 пункты)*

19) җирле әһәмияткә ия автомобиль юлларының сакланышын тәэмин итүгә муниципаль контрольне гамәлгә ашыру;

*(Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Шәһәр Советының 2011 елның 15 декабрендәге 15/7 номерлы Карары редакциясенең 19 пункты)*

19.1) шәһәр округы чикләрендә автомобиль транспортында, шәһәр җир өсте электр транспортында һәм юл хуҗалыгында муниципаль контрольне гамәлгә ашыру;

*(19.1 пункт Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Шәһәр Советының 2019 елның 1 августындагы 32/13 номерлы Карары белән кертелгән, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Шәһәр Советының 2021 елның 3 ноябрендәге 9/5 номерлы Карары редакциясе)*

20) җирле әһәмияткә ия автомобиль юлларын үстерү өлкәсендә инвестиция сәясәтенең төп юнәлешләрен эшләү;

21) җирле әһәмияткә ия гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын, күрсәтелгән автомобиль юллары участокларын түләүле нигездә файдалану һәм мондый файдалануны туктату турында карарлар кабул итү;

*(Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Шәһәр Советының 2011 елның 15 декабрендәге 15/7 номерлы Карары редакциясенең 21 пункты)*

21.1) җирле әһәмияткә ия гомуми файдаланудагы автомобиль юлларында урнашкан парковкаларны (парковка урыннарын) түләүле нигездә төзү һәм алардан файдалану турында һәм мондый файдалануны туктату хакында карарлар кабул итү;

*(Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Шәһәр Советының 2011 елның 15 декабрендәге 15/7 номерлы Карары редакциясенең 21.1 пункты)*

21.2) җирле әһәмияткә ия гомуми файдаланудагы автомобиль юлларында урнашкан парковкалар (парковка урыннары), шул исәптән түләүле нигездә, булдыру һәм алардан файдалану тәртибен билгеләү;

*(Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Шәһәр Советының 2011 елның 15 декабрендәге 15/7 номерлы Карары редакциясенең 21.2 пункты)*

21.3) җирле әһәмияткә ия гомуми файдаланудагы автомобиль юлларында урнашкан парковкаларны (парковка урыннарын) түләүле нигездә файдаланган өчен түләү күләмен билгеләү;

*(Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Шәһәр Советының 2011 елның 15 декабрендәге 15/7 номерлы Карары редакциясенең 21.3 пункты)*

22) җирле әһәмияткә ия гомуми файдаланудагы түләүле автомобиль юлларыннан, күрсәтелгән автомобиль юлларының түләүле участокларыннан түләүле нигездә җирле әһәмияткә ия гомуми файдаланудагы автомобиль юлларында урнашкан парковкалардан (парковка урыннарыннан) файдаланган өчен транспорт чараларын йөрткән өчен түләүнең максималь күләмен исәпләү методикасын һәм күләмен билгеләү;

*(Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Шәһәр Советының 2011 елның 15 декабрендәге 15/7 номерлы Карары редакциясенең 22 пункты)*

23) җирле әһәмияткә ия гомуми файдаланудагы автомобиль юллары исемлеген, җирле әһәмияткә ия булмаган гомуми файдаланудагы автомобиль юллары исемлеген раслау;

24) җирле әһәмияткә ия автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеген гамәлгә ашыру;

24.1) җирле әһәмияткә ия автомобиль юлларында, шул исәптән урам-юл челтәре объектларында, юл эшчәнлеген гамәлгә ашырганда, муниципаль берәмлек чикләрендә, шул исәптән, юл эшчәнлеген гамәлгә ашырганда, юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү чараларын гамәлгә ашыру:

юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү максатларында, муниципаль берәмлек чикләрендә җирле әһәмияткә ия автомобиль юлларында транспорт чаралары хәрәкәтен вакытлыча чикләү яисә туктату турында карарлар кабул итү;

муниципаль берәмлек территориясендә балаларның юл-транспорт имгәнүләрен кисәтү буенча чараларны тормышка ашыруда катнашу;

*(Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Шәһәр Советының 2011 елның 15 декабрендәге 15/7 номерлы Карары редакциясенең 24.1 пункты)*

ел саен (хисап елыннан соң килә торган елның 1 июленә кадәр) юллардагы авария-куркыныч участоклар исемлеген раслау һәм юл-транспорт һәлакәтләренең сәбәпләрен һәм шартларын бетерүгә юнәлдерелгән беренче чираттагы чараларны эшләү;

*(абзац Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Шәһәр Советының 2019 елның 1 августындагы 32/13 номерлы Карары белән кертелгән)*

24.2) җирле әһәмияткә ия гомуми файдаланудагы автомобиль юлларында юл хәрәкәтен оештыру һәм мониторинглау;

24.3) җирле әһәмияткә ия гомуми файдаланудагы автомобиль юлларында гомуми файдаланудагы парковкалар реестрын алып бару;

24.4) җирле әһәмияткә ия гомуми файдаланудагы автомобиль юлларында юл хәрәкәтен оештыруның техник чараларын урнаштыру, алыштыру, демонтажлау һәм карап тоту;

24.5) «Россия Федерациясендә юл хәрәкәтен оештыру һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Федераль закон белән җирле үзидарә органнары вәкаләтләренә кертелгән башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыру.

*(24.2-24.5 пунктлар Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Шәһәр Советының 2018 елның 27 апрелендәге 24/8 номерлы Карары белән кертелгән)*

25) җирле әһәмияткә ия автомобиль юллары буенча хәрәкәт иткәндә авыр транспорт чаралары китерә торган зыян күләмен билгеләү;

*(Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Шәһәр Советының 2017 елның 22 февралендәге 15/10 номерлы Карары редакциясенең 25 пункты)*

26) җирле әһәмияткә ия гомуми файдаланудагы автомобиль юлларына юл сервисы объектларын тоташтыру буенча хезмәт күрсәтүләр бәясен һәм исемлеген билгеләү;

27) җирле әһәмияткә ия гомуми файдаланудагы автомобиль юлларыннан файдаланучыларны мәгълүмат белән тәэмин итү;

28) билгеләнгән тәртиптә җирле әһәмияткә ия автомобиль юлларына исемнәр һәм идентификация номерларын бирү.

*(19-28 пунктлар Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Шәһәр Советының 2007 елның 25 декабрендәге 28/10 номерлы Карары белән кертелгән)*

**10. Торак мөнәсәбәтләре өлкәсендә:**

1) муниципаль торак фондын исәпкә алу;

2) Гражданнарны аз керемлеләр дип тану һәм аларга муниципаль торак фондыннан социаль наем шартнамәләре буенча торак урыннары бирү максатларында гаиләнең һәр әгъзасына туры килә торган керем күләмен һәм гаилә әгъзалары милкендәге һәм салым салынырга тиешле милек хакын билгеләү;

2.1) гражданнарны социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннары наем шартнамәләре буенча торак урыннары бирүгә мохтаҗлар дип тану максатларында гражданнарның һәм алар белән даими яшәүче гаилә әгъзаларының керемен һәм аларның салым салынырга тиешле милек хакын билгеләү;

2.2) гражданнарны социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннары наем шартнамәләре буенча торак урыннары бирүгә мохтаҗлар дип тану максатларында гражданнарның һәм алар белән даими яшәүче гаилә әгъзаларының кеременең максималь күләмен һәм аларның гаилә әгъзалары тарафыннан салым салынырга тиешле милекнең хакын билгеләү;

*(2.1, 2.2 пунктлар Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Шәһәр Советының 2014 елның 16 октябрендәге 33/17 номерлы Карары белән кертелгән)*

3) социаль наем шартнамәләре буенча бирелә торган торак урыннарына мохтаҗлар буларак гражданнарны билгеләнгән тәртиптә исәпкә алуны алып бару;

*(2 һәм 3 пунктлар Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Шәһәр Советының 2007 елның 25 декабрендәге 28/10 номерлы Карары белән кертелгән)*

3.1) социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча торак урыннары бирүгә мохтаҗ гражданнарны исәпкә алуны алып бару;

*(3.1 пункт Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Шәһәр Советының 2014 елның 16 октябрендәге 33/17 номерлы Карары белән кертелгән)*

3.2) торак законнары нигезендә социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча гражданнарга муниципаль торак фондыннан торак урыннары бирү;

*(3.2 пункт Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Шәһәр Советының 2015 елның 27 февралендәге 38/14 номерлы Карары белән кертелгән)*

4) муниципаль махсуслаштырылган торак фондта торак урыннар бирү;

4.1) полиция участок уполномоченные вазыйфасын биләп торучы хезмәткәргә һәм аның гаилә әгъзаларына хезмәткәрнең әлеге вазыйфаны биләү чорында торак урыны бирү;

*(4.1 пункт Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Шәһәр Советының 2020 елның 29 декабрендәге 4/7 номерлы Карары белән кертелгән)*

5) аз керемле гражданнарга муниципаль торак фондыннан социаль наем шартнамәләре буенча торак урыннарын билгеләнгән тәртиптә бирү;

*(5 пункт Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Шәһәр Советының 2007 елның 25 декабрендәге 28/10 номерлы Карары белән кертелгән)*

6) билгеләнгән тәртиптә торак булмаган биналарны торакка һәм торак биналарны торак булмаган биналарга күчерү турында карарлар кабул итү;

7) күпфатирлы йортта торак урыннарын үзгәртеп кору һәм яңадан планлаштыруны килештерү;

*(Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Шәһәр Советының 2019 елның 1 августындагы 32/13 номерлы Карары редакциясенең 7 пункты)*

8) Гамәлдән чыгарылган. – *(Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Шәһәр Советының 2006 елның 19 октябрендәге 15/4 номерлы Карары)*

8) муниципаль торак контролен гамәлгә ашыру;

*(Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Шәһәр Советының 2012 елның 20 декабрендәге 22/19 номерлы Карары редакциясенең 8 пункты)*

9) муниципаль һәм шәхси торак фондының торак урыннарын, Россия Федерациясе яки Татарстан Республикасы милкендә булган күпфатирлы йортлардан тыш, билгеләнгән тәртиптә яшәү өчен яраксыз дип тану, авария хәлендә һәм сүтелергә яки реконструкцияләнергә тиешле күпфатирлы йортлардан тыш;

*(9 пункт Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Шәһәр Советының 2007 елның 15 декабрендәге 28/10 номерлы Карары белән кертелгән, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Шәһәр Советының 2020 елның 17 июнендәге 40/3 номерлы Карары редакциясе)*

10) күпфатирлы йортта торак урыннарын үзгәртеп кору һәм (яки) яңадан планлаштыру шартлары һәм тәртибе нигезендә күпфатирлы йортта торак урынны үзгәртеп коруны һәм (яки) яңадан планлаштыруны килештерү яисә килештерүдән баш тарту турында карар кабул итүне раслый торган документ алу тәртибен билгеләү;

*(10 пункт Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Шәһәр Советының 2019 елның 1 августындагы 32/13 номерлы Карары белән кертелгән)*

**11. Халыкка элемтә, җәмәгать туклануы, сәүдә, көнкүреш хезмәте күрсәтү һәм эшмәкәрлек өлкәсендә хезмәт күрсәтү белән тәэмин итү өлкәсендә:**

3) элемтә операторларына универсаль элемтә хезмәтләре күрсәтүне оештыруда ярдәм итү;

4) товарларның аерым төрләрен ваклап сату рөхсәт ителә торган урыннарны билгеләү;

5) шәһәр территориясендә сәүдә, җәмәгать туклануы, халыкка көнкүреш хезмәте күрсәтү, элемтә, азык-төлек һәм эшкәртү сәнәгате предприятиеләренең мәгълүмат базасын алып бару, шул исәптән һәркем ала алырлык.

7) ваклап сату (сәүдә) челтәре өчен билгеләнгән тәртиптә урыннар бирү;

8) муниципаль сәүдә оешмаларының кулланучыларга көнкүреш һәм башка төр хезмәт күрсәтү режимын билгеләү;

*(Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Шәһәр Советының 2018 елның 11 декабрендәге 28/9 номерлы Карары редакциясенең 11 пункты)*

9) сәүдә, җәмәгать туклануы, халыкка көнкүреш хезмәте күрсәтү предприятиеләре арасында һөнәри конкурслар оештыру һәм үткәрү;

10) «Этил спиртын, алкогольле һәм спиртлы продукция җитештерүне һәм әйләнешен дәүләти җайга салу һәм алкогольле продукцияне куллануны (эчүне) чикләү турында» Федераль законда билгеләнгән компетенция чикләрендә алкогольле продукцияне, спиртлы продукцияне ваклап сату өлкәсендәге законнарның үтәлешен тикшереп торуны гамәлгә ашыру;

*(Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Шәһәр Советының 2018 елның 27 апрелендәге 24/8 номерлы Карары редакциясенең 11 пункты)*

11) бакчачылык һәм яшелчәчелек алып баруда ярдәм күрсәтү;

*(Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Шәһәр Советының 2018 елның 11 декабрендәге 28/9 номерлы Карары редакциясенең 11 пункты)*

12) «Кулланучылар хокукларын яклау турында» 1992 елның 7 февралендәге 2300-1 номерлы Россия Федерациясе Законында каралган кулланучылар хокукларын яклау чараларын гамәлгә ашыру;

*(Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Шәһәр Советының 2006 елның 19 октябрендәге 15/4 номерлы Карары редакциясенең 12 пункты, 2018 елның 11 декабрендәге 28/9 номерлы Карары редакциясе)*

13) авыл хуҗалыгы җитештерүен үстерү, авыл хуҗалыгы продукциясенең чимал һәм азык-төлек базарын киңәйтү өчен шартлар тудыру, кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерүгә ярдәм күрсәтү, социаль юнәлешле коммерцияле булмаган оешмаларга, хәйрия эшчәнлегенә һәм иреклеләргә (волонтерлыкка) булышлык итү;

*(Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Шәһәр Советының 2007 елның 25 декабрендәге 28/10 номерлы Карары редакциясенең 13 пункты, 2018 елның 1 августындагы 32/13 номерлы Карары)*

13.1) милли һәм җирле социаль-икътисадый, экологик, мәдәни һәм башка үзенчәлекләрне исәпкә алып, иреклеләргә (волонтерлыкка) ярдәм күрсәтүгә

юнәлдерелгән чараларны үз эченә алган муниципаль программаларны (ярдәмче программаларны) формалаштыру һәм гамәлгә ашыру;

13.2) җирле үзидарә органнарының, муниципаль учреждениеләрнең ирекleләр (волонтерлык) эшчәнлеген оештыручылар, ирекleләр (волонтерлык) оешмалары белән үзара хезмәттәшлеге тәртибен раслау;

13.3) ирекleләр (волонтерлык) эшчәнлеген оештыручыларга, ирекleләр (волонтерлык) оешмаларына, шул исәптән аларның муниципаль учреждениеләр һәм башка оешмалар, социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешмалар, дәүләт һәм муниципаль учреждениеләр белән үзара хезмәттәшлегендә, ирекleләр (волонтерлык) эшчәнлеген оештыручыларга, һәм ирекleләр (волонтер) оешмаларына оештыру, мәгълүмати, методик һәм башка ярдәм күрсәтүне тәэмин итүче дәүләт һәм муниципаль учреждениеләргә ярдәм күрсәтү;

*(13.1-13.3 пунктлар Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Шәһәр Советының 2019 елның 6 декабрендәге 34/14 номерлы Карары белән кертелгән)*

14) Башкарма комитетның муниципаль хокукый акты нигезендә, законнарда билгеләнгән очраклардан тыш, эшмәкәрлек һәм инвестиция эшчәнлеге субъектлары өчен муниципаль норматив хокукый актларда яңа яки элек үзгәртелгән муниципаль хокукый актлар проектларының җайга салу йогынтысын бәяләүне үткәрә;

*(14 пункт Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Шәһәр Советының 2017 елның 22 февралендәге 15/10 номерлы Карары белән кертелгән)*

**12. Гражданнарның сәламәтлеген саклау өлкәсендә:**

1) гражданнарга түләүсез медицина ярдәме күрсәтү буенча дәүләт гарантияләренең территориаль программасы һәм «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законда билгеләнгән вәкаләтләр чикләрендә Россия Федерациясе субъекты законы нигезендә халыкка медицина ярдәме күрсәтү өчен шартлар тудыру;

2) Россия Федерациясе субъекты законы нигезендә, муниципаль берәмлек халкына, шул исәптән массакүләм мәгълүмат чаралары аша муниципаль берәмлек территориясендә социаль әһәмияткә ия авырулар һәм әйләнә-тирәдәгеләр өчен куркыныч тудыра торган авырулар таралу мөмкинлеге турында ел саен статистик мәгълүматлар нигезендә хәбәр итү, шулай ук эпидемияләр барлыкка килү куркынычы турында хәбәр итү;

3) халыкка санитар-гигиеник белем бирүдә һәм кан һәм (яки) аның компонентлары донорлыгын пропагандалауда катнашу;

4) муниципаль берәмлек территориясендә гадәттән тыш хәлләр вакытында кешеләрнең гомерен саклап калуга һәм сәламәтлеген саклауга юнәлдерелгән чараларны гамәлгә ашыруда катнашу, гадәттән тыш хәл зонасындагы медик-санитар хәл һәм күрелә торган чаралар турында халыкка хәбәр итү;

5) муниципаль берәмлек территориясендә авыруларны профилактикалау һәм сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру чараларын Россия Федерациясе субъекты законы нигезендә гамәлгә ашыру;

6) медицина хезмәткәрләрен һәм фармацевтика хезмәткәрләрен медицина оешмаларында эшләү өчен җәлеп итү максатларында «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә уңайлы шартлар тудыру.

7) муниципаль берәмлекләр территорияләрендә гражданнарның сәламәтлеген әйләнә-тирә тәмәке төтене йогынтысыннан, тәмәке куллану һәм никотинсыз продукция куллану нәтиҗәләреннән саклау чараларын гамәлгә ашыруда катнашу;

8) сәламәтлек саклау өлкәсендәге законнар нигезендә тиешле вәкаләтләр тапшырылган очракта, муниципаль сәламәтлек саклау системасының медицина оешмаларында тәмәкене яки никотинлы продукцияне куллануны туктатуга, тәмәкегә (никотинга) бәйле рәвештә тәмәке куллану (никотин) нәтиҗәләрен дәвалауга юнәлдерелгән медицина ярдәме күрсәтүне оештыруны тәэмин итү;

9) халыкка тиешле муниципаль берәмлек территориясендә тәмәке тарту һәм никотинлы продукция куллану масштабы, аларны куллануны киметү буенча гамәлгә ашырыла торган һәм (яки) планлаштырыла торган чаралар турында, шул исәптән әйләнә-тирә тәмәке төтененең, никотинлы продукция кулланганда бүлеп чыгарыла торган матдәләрнең йогынтысын, тәмәкене һәм никотинлы продукцияне куллануны киметүгә юнәлдерелгән чараларны тормышка ашыруның нәтиҗәлелеген мониторинглау һәм бәяләү нигезендә, халыкка хәбәр итү;

---

*(Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Шәһәр Советының 2020 елның 29 декабрендәге 4/7 номерлы Карары редакциясенең 7-9 пунктлары, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Шәһәр Советының 2012 елның 5 июлендәге 19/15 номерлы Карары редакциясенең 12 өлеше)*

---

10) алкогольле, наркотик яки башка токсик исерек хәлдә булган затларга ярдәм күрсәтү чараларын гамәлгә ашыру;

---

*(10 пункт Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Шәһәр Советының 2021 елның 27 маендагы 7/6 номерлы Карары белән кертелгән)*

---

11) муниципаль берәмлекләр территорияләрендә эпидемиягә каршы, эпизоотиягә каршы, эпифитотиягә каршы чараларны гамәлгә ашыруда катнашу.

**13. Мәдәният өлкәсендә:**

1) халыкка китапханә хезмәте күрсәтүне оештыру, шәһәр китапханә фондларын комплектлауны һәм аларның сакланышын тәэмин итүне оештыру;

2) шәһәр халкын мәдәният оешмалары хезмәтләре белән тәэмин итү һәм ял оештыру өчен шартлар тудыру;

3) җирле традицион халык сәнгатен үстерү өчен шартлар тудыру, шәһәрдә халык сәнгате һөнәрчелеген саклау, яңарту һәм үстерүдә катнашу;

4) муниципаль милектә булган мәдәни мирас объектларын саклау, алардан файдалану һәм популярлаштыру;

5) җирле (муниципаль) әһәмияткә ия мәдәни мирас объектларын дәүләт тарафыннан саклау;

6) җирле (муниципаль) әһәмияткә ия тарихи-мәдәни тыюлыкны оештыру тәртибен билгеләү;

7) милләтара һәм конфессияара татулыкны ныгытуга, шәһәр территориясендә яшәүче Россия Федерациясе халыкларының телләре һәм мәдәнияте үсешенә ярдәм күрсәтүгә һәм үстерүгә, төп аз санлы халыкларның һәм башка милли азчылыкның хокукларын тормышка ашыруга, мигрантларның социаль һәм мәдәни адаптациясен тәэмин итүгә, милләтара (этникара) конфликтларны профилактикалауга юнәлтелгән чаралар эшләү һәм гамәлгә ашыру;

*(Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Шәһәр Советының 2019 елның 1 августындагы 32/13 номерлы Карары редакциясенең 7 пункты)*

8) муниципаль милектә булган мәдәни мирас объектларына инвалидлар керү өчен шартлар белән тәэмин итү;

9) «Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарихи һәм мәдәни һәйкәлләр) турында» 2002 елның 25 июнендәге 73-ФЗ номерлы Федераль законда һәм башка федераль законнарда каралган башка вәкаләтләр;

*(Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Шәһәр Советының 2018 елның 11 декабрендәге 28/9 номерлы Карары редакциясенең 13 өлеше)*

**14. Мәгариф өлкәсендә:**

1) муниципаль мәгариф оешмаларында төп гомуми белем бирү программалары буенча һәркем ала алырлык һәм түләүсез мәктәпкәчә, башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем бирүне оештыру (федераль дәүләт белем бирү стандартлары нигезендә төп гомуми белем бирү программаларын гамәлгә ашыруны финанс ягыннан тәэмин итү вәкаләтләреннән тыш);

2) муниципаль белем бирү оешмаларында балаларга өстәмә белем бирүне оештыру (финанс белән тәэмин итү Россия Федерациясе субъекты дәүләт хакимияте органнары тарафыннан гамәлгә ашырыла торган балаларга өстәмә белем бирүдән тыш);

3) муниципаль белем бирү оешмаларында балаларны күзәтү һәм карау, карап тоту өчен шартлар тудыру;

4) муниципаль белем бирү оешмаларын төзү, үзгәртеп кору, бетерү, муниципаль белем бирү оешмаларын гамәлгә кую функцияләрен һәм вәкаләтләрен гамәлгә ашыру;

5) муниципаль белем бирү оешмаларының биналарын һәм корылмаларын карап тотуны тәэмин итү, алар янәшәсендәге территорияләрне төзекләндерү;

6) мәктәпкәчә, башлангыч гомуми, төп гомуми һәм урта гомуми белем бирү программалары буенча укытылырга тиешле балаларны исәпкә алу, муниципаль белем бирү оешмаларын шәһәрнең конкрет территорияләренә беркетү;

7) үз вәкаләтләре чикләрендә балаларның каникул вакытында ялын оештыруны тәэмин итү чараларын, шул исәптән аларның тормыш һәм сәламәтлеге куркынычсызлыгын тәэмин итү чараларын гамәлгә ашыру;

*(7 пункт Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Шәһәр Советының 2017 елның 22 февралендәге 15/10 номерлы Карары белән кертелгән)*

*(Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Шәһәр Советының 2014 елның 21 февралендәге 29/17 номерлы Карары редакциясенең 14 өлеше)*

**15 Физкультура һәм спортны үстерү өлкәсендә:**

1) җирле шартлар һәм мөмкинлекләрне исәпкә алып, физик культура һәм спортны үстерүнең төп бурычларын һәм юнәлешләрен билгеләү, физик культура һәм спортны үстерүнең муниципаль программаларын кабул итү һәм тормышка ашыру;

2) шәһәр территориясендә массакүләм спортны, балалар-яшүсмерләр спортын һәм мәктәп спортын үстерү.;

3) «Россия Федерациясендә физик культура һәм спорт турында» Федераль законның 22 статьясы нигезендә спорт разрядларын һәм спорт судьяларының квалификация категорияләрен бирү;

4) халыкның төрле төркемнәре арасында, шул исәптән инвалидлар, сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән затлар арасында физик культура һәм спортны популярлаштыру;

5) гражданнарның яшәү урыны һәм ял урыны буенча физкультура-спорт эшен оештыру, шул исәптән инвалидлар, сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән затларга физик культура һәм спорт белән шөгыльләнү өчен шартлар тудыруны да кертеп, шулай ук муниципаль рәсми физкультура чаралары һәм спорт чараларын оештыру һәм уздыру, шул исәптән:

а) ГТО комплексын тормышка ашыру буенча физкультура чараларын һәм спорт чараларын үз эченә алган шәһәрнең физкультура чараларының һәм спорт чараларының календарь планнарын раслау һәм тормышка ашыру;

б) шәһәрнең рәсми физкультура чараларын һәм спорт чараларын медицина ягыннан тәэмин итүне оештыру;

6) үз вәкаләтләре кысаларында шәһәр территориясендә рәсми физкультура чаралары һәм спорт чаралары үткәргәндә җәмәгать тәртибен һәм җәмәгать куркынычсызлыгын тәэмин итүгә ярдәм күрсәтү;

7) шәһәрнең спорт җыелма командаларын әзерләү өчен шартлар тудыру, шәһәрнең спорт җыелма командалары формалашырга мөмкин булган спорт төрләрен билгеләү, мондый командаларны формалаштыру һәм тәэмин итү тәртибен раслау, аларны муниципальара һәм региональ спорт ярышларында катнашу өчен җибәрү;

8) шәһәр һәм Татарстан Республикасының спорт җыелма командалары өчен спорт резервын әзерләүне тәэмин итүдә катнашу, шәһәр тарафыннан төзелгән һәм спорт әзерлеге федераль стандартлары нигезендә эшләнгән спорт

әзерлеге программаларын гамәлгә ашыручы оешмалар эшчәнлеген тәэмин итүне, физик культура һәм спорт өлкәсендә өстәмә гомуми белем бирү программаларын, шулай ук шәһәр төзегән һәм спорт әзерлеге программаларын гамәлгә ашыручы, спорт әзерлеге федераль стандартлары нигезендә эшләнгән спорт әзерлеге программаларын гамәлгә ашыручы оешмаларның Россия Федерациясе законнары нигезендә спорт әзерлеге федераль стандартлары үтәүләрен тикшереп торуны гамәлгә ашыру;

9) коммерцияле булмаган оешмаларга ГТО комплексы сынаулары нормативларын (тестларын) үтәүне бәяләү хокукы бирү;

10) Россия Федерациясе законнары һәм шәһәр Уставы нигезендә билгеләнгән башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыру.

---

*(Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Шәһәр Советының 2021 елның 27 маендагы 7/16 номерлы Карары редакциясенең 15 өлеше)*

---

**16. Яшьләр сәясәте өлкәсендә:**

1) яшьләр сәясәтен тормышка ашыруда катнашу;

2) шәһәр округы территориясендә яшьләрнең хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен тәэмин итү һәм яклау чараларын эшләү һәм тормышка ашыру;

3) шәһәр округы территориясендә яшьләр белән эшләү чараларын оештыру һәм уздыру;

4) яшьләр сәясәтен тормышка ашыруның төп юнәлешләре буенча муниципаль программаларны эшләү һәм тормышка ашыру;

5) шәһәр округы территориясендә яшьләр сәясәтен тормышка ашыру мониторингын оештыру һәм гамәлгә ашыру;

6) федераль законнарда билгеләнгән яшьләр хокукларын тормышка ашыру өлкәсендә башка вәкаләтләр.

---

*(Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Шәһәр Советының 2021 елның 3 ноябрендәге 9/5 номерлы Карары редакциясенең 16 өлеше)*

---

**17. Су мөнәсәбәтләре өлкәсендә:**

1) муниципаль милектә булган су объектларын саклау чараларын гамәлгә ашыру;

2) суның тискәре йогынтысын булдырмау һәм аның нәтиҗәләрен бетерү буенча чараларны гамәлгә ашыру;

3) шәһәр территориясендә урнашкан гомуми файдаланудагы су объектларында судан файдалануны чикләү турында халыкка хәбәр итү, гражданнарга мондый чикләүләр турында мәгълүмат бирү;

4) судан файдалануны чикләү турында карар кабул итү;

5) билгеләнгән тәртиптә муниципаль милектә булган су объектларын яки мондый объектларның бер өлешен файдалануга бирү;

6) Шәһәр Советы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә муниципаль милектә булган су объектларыннан файдаланган өчен түләү исәпләү һәм алу;

7) билгеләнгән тәртиптә су законнарын бозуларны туктату турында кисәтүләр чыгару;

8) федераль законнар нигезендә судан файдалануны туктатып тору;

9) үз компетенциясе чикләрендә билгеләнгән тәртиптә су объектларыннан файдалануны муниципаль ихтыяҗлар өчен файдалану кирәклеге барлыкка килгән очракларда мәҗбүри туктатуны гамәлгә ашыру.

*(17 өлеш Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Шәһәр Советының 2006 елның 19 октябрендәге 15/4 номерлы Карары белән кертелгән)*

**18. Башкарма комитет муниципаль берәмлек исеменнән төзелә торган шартнамәләрне терки.**

*(Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Шәһәр Советының 2007 елның 4 июлелендәге 23/4 номерлы Карары редакциясенең 18 өлеше)*

18.1. Башкарма комитет шәһәр территориясендә муниципаль-шәхси партнерлык үсешен тәэмин итә.

18.2. Башкарма комитет муниципаль контрольне гамәлгә ашыруга вәкаләтле орган булып тора.

Муниципаль контроль төрләре реестры Башкарма комитет тарафыннан Россия Федерациясе Хөкүмәте раслаган контроль төрләренең бердәм реестрын формалаштыру һәм алып бару кагыйдәләре нигезендә алып барыла.

**Муниципаль контроль өлкәсендә Башкарма комитет вәкаләтләренә керә:**

1) Муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда дәүләт контроле (күзәтчелеге), муниципаль контроль өлкәсендә бердәм дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыруда катнашу;

2) муниципаль берәмлек территориясендә муниципаль контрольне оештыру һәм гамәлгә ашыру;

3) «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль закон, башка федераль законнар нигезендә башка вәкаләтләр.

*(Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Шәһәр Советының 2021 елның 3 ноябрендәге 9/5 номерлы Карары редакциясенең 18.2 өлеше)*

19. Башкарма Комитет Россия Федерациясе законнары, Татарстан Республикасы законнары, әлеге Устав, башка муниципаль хокукый актлар нигезендә башка вәкаләтләргә ия.

*(Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Шәһәр Советының 2006 елның 19 октябрендәге 15/24 номерлы Карары редакциясенең 19 өлеше)*